**ХАЛЫК ҖЫЕНЫ КАРАРЫ**

Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Күәм авыл җирлеге Әйшияз торак пунктында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында

"19" ноябрь 2023 ел. № 1

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 06.10.2003 ел №131-ФЗ Федераль законның 25.1, 56 статьясы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 28.07.2004 ел №45-ТРЗ Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, 2023 елның 19 ноябрендә «Сез 2024 елда Күәм авыл җирлеге Әйшияз торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган яшәүчегә, көндезге уку формасы буенча белем алучы студентлардан, 80 яшьтән өлкәнрәк гражданнардан, 1 нче төркем инвалидлардан, мобилизацияләнгән гражданнар һәм аларның гаилә әгъзаларыннан, РФ Оборона министрлыгы белән контракт төзегән хәрби хезмәткәрләр, аларның гаилә әгъзаларыннан тыш,500 сум күләмендә үзара салым кертү һәм бу акчаларның җирле әһәмияткә ия булган түбәндәге сорауларны хәл итүгә юнәлтү белән килешәсезме:

- Әйшияз авылы зираты территориясен чистарту (агач һәм куаклар кисү), эшләр һәм хезмәтләр өчен түләү;

«РИЗА» «КАРШЫ»

мәсьәләсе буенча халык җыены нәтиҗәләре белән беркетмә төзелде.

Халык җыены нәтиҗәләре турындагы беркетмә нигезендә:

Сайлау хокукына ия булган җыенда катнашучылар исемлегенә 152 (бер йөз илле ике) кеше кертелгән, җыенда катнашучылар саны 82 (сиксән ике) кеше.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча халык җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:

"Әйе» позициясе өчен халык җыенында катнашучы 79 (җитмеш тугыз) кеше тавыш бирде;

«Юк» позициясе өчен җыенда катнашучыларның 3 (өч) кеше тавыш бирде.

Бәян ителгәннәрдән чыгып, халык җыены карар итте:

1. Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Күәм авыл җирлеге Әйшияз авылында узган халык җыенын - узган дип, халык җыены нәтиҗәләрен – дөрес дип танырга.

2."Сез 2024 елда Күәм авыл җирлеге Әйшияз торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган яшәүчегә, көндезге уку формасы буенча белем алучы студентлардан, 80 яшьтән өлкәнрәк гражданнардан, 1 нче төркем инвалидлардан, мобилизацияләнгән гражданнар һәм аларның гаилә әгъзаларыннан, РФ Оборона министрлыгы белән контракт төзегән хәрби хезмәткәрләр, аларның гаилә әгъзаларыннан тыш, 500 сум күләмендә үзара салым кертү һәм бу акчаларның җирле әһәмияткә ия булган түбәндәге сорауларны хәл итүгә юнәлтү белән килешәсезме:

- Әйшияз авылы зираты территориясен чистарту (агач һәм куаклар кисү), эшләр һәм хезмәтләр өчен түләү.

3.Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Күәм авыл җирлеге Әйшияз авылында узган халык җыены нәтиҗәләрен авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында игълан итәргә.

4.Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Күәм авыл җирлеге Әйшияз авылында узган халык җыены нәтиҗәләрен Әтнә муниципаль районының Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә http://atnya.tatarstan.ru. веб-адресы буенча һәм “Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында" http://pravo.tatarstan.ru веб-адрес буенча урнаштырырга.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Күәм авыл җирлеге башлыгы Хасбиуллин И.И.